
# 1 кечкенәләр төркемендә балаларны шәхси гигиена әйберләре белән таныштыру


# Йомшак су, йөгерек су.




# Хуш исле шома,үзе чисталап юа.



Эчтә ята ул посып,
Чыгарам аны кысып,
Щетка белән гөмергә
Яшиләр бергә - бергә.




Һәр көн иртән ал кулыңа,
Миннән башла эшеңне.
Паста белән мин чистартам,
Ап – ак итеп тешеңне.



Озын тешләрем белән.
Чәч буе йөгерәм.



Аккош кебек ак кына,йомшак кына,пакъ кына. Сыйпый мине чәчемнән, элеп куям читеннән.



Төчкерсәк тә, йөткерсәк тә,
һәр вакыт ярдәмгә килә.



Кызмы ул, малаймы ул,
Нәкъ булганча күрсәтер,
Нәрсә соң бу, кем әйтер?



# Физминутка

"Күрсәт әле үскәнем"

Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек кулны юалар?
Менә шулай, менә шулай
Шулай кулны юалар.

Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек битне юалар?
Менә шулай, менә шулай
Шулай битне юалар.

Күрсәт әле,үскәнем,
Ничек теш чистарталар?
Менә шулай, менә шулай
Шулай теш чистарталар.

Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек битне сөртәләр?
Менә шулай, менә шулай
Шулай битне сөртәләр.


Сәләмәт булыгыз!